РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ ЯНУРУСОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
Село Янурусово, улица Ленина, дом
43а, 423370 Телефон 4-10-19

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯНУРЫС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
Ленин урамы,43а йорт, Янурыс авылы,
423370 Телефон: 4-10-19

ОГРН 1031604000757 ИНН/КПП 1636001403/163601001 ОКАТО 92253884000

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**№22** **12.11.2018 ел**

**Сарман муниципаль районының «Янурыс авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 31 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 июлендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Янурыс авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Янурыс авыл җирлегендә Янурыс авыл җирлегенең 2007 елның 7 июлендәге 13 номерлы карары белән расланган гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә, Сарман районы прокуратурасының 02-07-01/2018 номерлы протесты нигезендә, карар ителде:

1. «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Янурыс авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Янурыс авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2013 елның 4апрелендәге 4 номерлы карарына (кушымтада) үзгәреш кертергә.
2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга һәм http/ sarmanovo.tatarstan.ru веб-адрес буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Сарман муниципаль районның рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенә йөклим.

Янурыс авыл җирлеге
Советы рәисе А.А.Мөхәммәдиева

**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җирлеге Советының 2018 елның 12 ноябрендәге 22 номерлы карарына кушымта**

**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Янурыс авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү**

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җирлеге Советының 2013 елның 4 апрелендәге 4 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Янурыс авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә, шәһәр төзелеше регламентлары белән түбәндәге шәһәр төзелеше зоналарына карата җир кишәрлекләренең чик (минималь һәм (яки) максималь) күләмнәре һәм рөхсәт ителгән төзелеш, реконструкция объектларының чик параметрлары өлешендә үзгәрешләр, шулай ук җир кишәрлекләрен һәм капиталь төзелеш объектларын куллануны чикләү өлешендә үзгәрешләр кертергә:

14 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Куллануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында карар проекты, әлеге статьяның нигезләмәләрен исәпкә алып, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясында билгеләнгән тәртиптә үткәрелә торган иҗтимагый фикер алышуларда яисә гавами тыңлауларда каралырга тиеш. Әгәр җир кишәрлеген яисә капиталь төзелеш объектын файдалануның рөхсәт ителгән төре әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясарга мөмкин булса, җәмәгать фикер алышулары яки гавами тыңлаулар мондый тискәре йогынтыны куркыныч астына куйган җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары хокук ияләре катнашында уздырыла».

14 статьяның 4 пунктында «Комиссия» сүзен «Җәмәгать фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар оештыручы» сүзләренә алмаштырырга, «бирү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар» сүзләрен «бирү турында карар проекты буенча җәмәгать фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар» сүзләренә алмаштырырга.

5 статьяның 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 4.1 статьясындагы 4 өлешенең 2 пункты һәм 5.1 статьясындагы 2 өлеше 2 пункты нигезендә җәмәгать фикер алышуларында яки гавами тыңлауларда каралырга тиешле проектны һәм аңа карата мәгълүмати материалларны урнаштыру һәм мондый проект экспозициясен яки экспозицияләрен Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 статьясындагы 12 өлеше нигезендә узган җәмәгать фикер алышуларында һәм гавами тыңлауларда катнашучылар мондый проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертергә хокуклы:

Россия Федерациясе кодексы идентификацияләүгә, мондый проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертергә хокуклы:

1)рәсми сайт яисә мәгълүмат системалары ярдәмендә (җәмәгать фикер алышулар үткәрелгән очракта);

2)гавами тыңлауларда катнашучыларның җыелышын яисә җыелышларын уздыру барышында язма яисә телдән (гавами тыңлаулар үткәрелгән очракта);

3)җәмәгать фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар оештыручы адресына язма рәвештә;

4)җәмәгать фикер алышуларда яисә гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект экспозициясенә килүчеләрне исәпкә алу кенәгәсендә (журналында) язу юлы белән.».

14 статьяның 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Җәмәгать фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә басылып чыккан көнгә кадәр «Янурыс авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге халкына хәбәр итүдән алып җәмәгать фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар уздыру срогы «Янурыс авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы һәм (яисә) муниципаль хокукый актлары белән билгеләнә һәм бер айдан артык була алмый.».

14 статьяның 10 пунктында «бирү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар» сүзләрен «бирү турында карар проекты буенча җәмәгать фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар» сүзләренә алмаштырырга.

30 статьяның 10 пунктында «гавами тыңлаулар» сүзләрен «җәмәгать фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар» сүзләренә алмаштырырга.